ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) законнарда билгеләнгән очракларда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;»;

2) 5 статьяда:
а) исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;
б) 1 өлештә:
4 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарын» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарын» сүзләренә алмаштырырга;
7 пунктның «б» пунктчасындагы дүртенче абзацында «федераль яки» сүзләрен «федераль милеккә, Россия Федерациясе субъектлары милкенә,» сүзләренә алмаштырырга;
8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«8) законнарда билгеләнгән очракларда хуҗалык җәмгыятьләренең идарә итү һәм тикшереп тору органнарында Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә эш итүче вәкилләрне билгеләп кую, сайлау өчен күрсәтү, билгеләп куюны һәм сайлау өчен күрсәтүне килештерү;»;

в) 2 өлешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяда:

а) 4 өлештә «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең моңа вәкаләтле башка органнары» сүзләрен «моңа вәкаләтле республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлешнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 29 сентябрь
№ 91-ТРЗ